**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2024елның 29 октябре 1934 номер

# КАРАР

**«Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июнендәге 1720 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 284-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июнендәге 1720 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертергә:

1) 2.8.2.1 пунктының 6 пунктчасы:

– "линия объектлары булган инженерлык корылмаларына капиталь ремонт ясау максатларында, шулай ук мондый инженерлык корылмалары участокларына (өлешләренә) капиталь ремонт ясау максатларында гавами сервитут билгеләү очрагыннан тыш" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э.В. Хисмәтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**